ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.03.2019 Алексеевск ш.т.б. № 99

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Опека һәм попечительлек бүлеге тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары турында» 2016 елның 26 июлендәге 305 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Федераль закон таләпләренә туры китерү максатында Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Опека һәм попечительлек бүлеге тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары турында» 2016 елның 26 июлендәге 305 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

**карар бирәм:**

1. 1-10 кушымталарның 5 Бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә: «Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең, шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законының 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе.

5.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителгән (гамәлгә ашырыла торган) гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү хокукына ия.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законының 15.1 статьясында күрсәтелгән хезмәт күрсәтү турындагы гарызнамәне теркәү вакытын бозу»;

- дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу. Күрсәтелгәночракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), күпфункцияле үзәк хезмәткәренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә йөкләнгән очракта мөмкин;

- мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен муниципаль хокукый актлар белән каралмаган документлар, мәгълүмат яисә гамәлләр башкару, тәкъдим итү яки гамәлгә ашыру таләбе;

- мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

- әгәр баш тарту нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту.Күрсәтелгәночракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), күпфункцияле үзәк хезмәткәренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә йөкләнгән очракта мөмкин;

- мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге муниципаль хокукый актлары белән күздә тотылмаган түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә түләү таләп итү;

- дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәк яки күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган дәүләт хезмәте күрсәтүче оешмаларның яисә аларның хезмәткәрләренең дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләр кертүнең билгеләнгән срогын бозу.Күрсәтелгәночракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), күпфункцияле үзәк хезмәткәренә карата судка кадәр

(судтан тыш) шикаять биру, шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә йөкләнгән очракта мөмкин;

- дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

- федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм норматив актлары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актлары белән күздә тотылмаган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору.Күрсәтелгәночракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), күпфункцияле үзәк хезмәткәренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә йөкләнгән очракта мөмкин;

- дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тарткан вакытта яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдә кирәкле документларның яисә мәгълүматның булмавы һәм (яисә) дөрес булмавы яисәтөгәллеге күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү. Күрсәтелгәночракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), күпфункцияле үзәк хезмәткәренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә йөкләнгән очракта мөмкин.

5.2. Шикаять кәгазьдә, электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы (алга таба – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы) дәүләт хакимиятенең тиешле органына яисә халыкка хокукый белем бирү органына (алга таба – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы), шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларга язмача тапшырыла.Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата булган шикаятьләрюгары органга (булган очракта) бирелә яисә ул булмаганда турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата булган шикаятьләр әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә тапшырыла.Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата булган шикаятьләр күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга яисә Татарстан Республикасының норматив хокукый акты белән билгеләнгән вәкаләтле вазыйфаи затка тапшырыла.«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешма хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата булган шикаятьләр.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, аның вазыйфаи заты, дәүләт хезмәткәре, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата булган шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның рәсми сайтын, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең бердәм порталыннан яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең региональ порталыннан файдаланып, күпфункцияле үзәк аша җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында да кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата булган шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрен, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтын, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең региональ порталын файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында да кабул ителергә мөмкин. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәре, әлеге оешмаларның рәсми сайтлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең региональ порталын кулланып почта аша җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында да кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының, дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәк, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять белдерелә торган, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның җитәкчеләре һәм (яки) хезмәткәрләренең исеме;

- фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), мөрәҗәгать итүчефизик зат булса, аның яшәү урыны яисә мөрәҗәгать итүче юридик зат булса, аның исеме һәм урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

- дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәк, аның хезмәткәренең, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында белешмәләр;

- мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының, күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәгән дәлилләр.Мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (булганда) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга,«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмага яисә югары органга (ул булган очракта)кергән шикаять теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмалармөрәҗәгать итүченең документларын кабул итүдән яисә җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарткан очракта, яки билгеләнгән срокны бозуга шикаять биргән очракта, мондый төзәтү теркәлгән көннән соң биш эш көне эчендәкарап тикшерелергә тиеш.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар беләнкаралмаган түләүакчаларын кире кайтару рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарталар.

5.7. Шикаятьне карау барышында яисә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракташикаятьләрне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура

органнарына юллый.

Шикаять тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиеш дип табылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә биргән  җавапта «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 8 өлешендә күрсәтелгәнчәдәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларындадәүләт хезмәте күрсәтүче органның, күпфункцияле үзәкнең яки «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешманың гамәлләре турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу максатларында мөрәҗәгать итүчегә башкарылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаятьне канәгатьләндерергә тиеш түгел дип тану очрагында, мөрәҗәгать итүчегә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 8 өлешендә күрсәтелгәнчә,кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат булган җавап бирелә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны опека һәмпопечительлек бүлеге начальнигы Е. П. Гореловага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К.Кадыйров**